| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.09.2024 г.Лениногорск № 1215

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 16 августындагы 747 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлеген арендага, милеккә торглар үткәрмичә түләп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 16 августындагы 747 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлеген арендага, милеккә торглар үткәрмичә түләп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.8.2.1 пунктының 8-10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан;

9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы

үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән очракта, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, территория чикләрендә урнашкан;

10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән булса, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлегеннән төзелгән;».

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Галимова Л.М.
5-44-72